РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 7 декабре № 53

«Мөлкәткә салым турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 31 номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә, «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына яраклаштырып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 31 номерлы «Физик затлар милкенә салым турында» карарына 2.3 пунктын өстәп, түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:

«2.3. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Түбән Кама шәһәрендә яшәү урыны буенча теркәлгән Россия Федерациясе гражданнарын, шулай ук Түбән Кама шәһәрендә яшәү урыны буенча теркәлгән Россия Федерациясе гражданнарын, хәрби хезмәткәрләрне һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларны, - салым салу объектының хуҗаларын һәм салым түләүчеләре аның гаилә әгъзаларын, шул ук объектта милек хокукына ия булучыларны мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.

Гаилә әгъзаларына аның белән бергә теркәлгән ир (хатын), балигъ булмаган балалар (шул исәптән тәрбияләнүчеләр) һәм ата-аналар керә.

Ташлама түбәндәге салым объектларына карата бирелә:

1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә, торак йорт яки торак йортның бер өлеше;

2) гараж яки машина урыны;

3) төзелеп бетмәгән объект, әгәр мондый объектның проектлана торган максаты торак йорт булса.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.Х. Муллин